**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕТУРМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ТОРМЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 57-3-12, факс 57-3-12

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**28 .10. 2025** **№ 2**

**2026 елда гражданнарга үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Кече Тормы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Олы Тормы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм::

1. 2025 елның 12 ноябрендә Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Кече Тормы авылы, Җәлил урамы, 19а йорт адресы буенча урнашкан Кече Тормы авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Кече Тормы торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 9 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Кече Тормы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итәргә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы сез (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр) һәм аларның гаилә әгъзалары, атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балаларны; махсус хәрби операциядә һәлак булган катнашучыларның (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгәннәрне, ирекле хезмәткәрләрне) гаилә әгъзаларын, атап әйткәндә: ата-аналарны, ир белән хатынны, балигъ булган балаларны һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Кече Тормы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларны ремонтлау, вак таш белән капланган чокырларны ремонтлау, вак таш сатып алу, ташу, салу, эш өчен килешү буенча түләү)?»

» КАРШЫ «РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Тормы авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Тормы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка

җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Н.Г.Салихов**